| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ КАВЗИЯКОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КӘҮҖИЯК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ |
|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

22 нче ноябрь 2024 ел №17

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 2024 елның 30 сентябрендәге 338-ФЗ номерлы Федераль законның 1 абзацы 16 статьясына үзгәреш кертү хакында, «Сарман муниципаль районының «Кәүҗияк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Кәүҗияк авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Кәүҗияк авыл җирлегенең 2022 елның 14 февралендәге 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Кәүҗияк авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1) 6.3 пункты. түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «6.3. Җирле үзидарә органы җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын бетерү максатларында, алар тиешле вазыйфаны биләгән чорда әлеге җирле үзидарә органының сайланулы профсоюз органында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен яклый алмый.»;

2) 9.3 пунктның 5 пунктчасында «һәм квалификация турында» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Кәүҗияк авыл җирлеге
Башлыгы Ф.Ә.Хөснетдинов